**МИНИСТЕРСТВО ПРОСВЕЩЕНИЯ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ**
**Министерство образования Республики Татарстан**
**Муниципальное образование Лаишевского муниципального района Республики Татарстан**
**МБОУ "Многопрофильный лицей "Инноватика"**

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ
Сертификат: 4310092c7836588cd77cd110bcf62049e2ce6fdc
Владелец: Булатова Наталья Сергеевна
Действителен: с 08.07.2024 до 01.10.2025

| РАССМОТРЕНО | СОГЛАСОВАНО | УТВЕРЖДЕНО |
| --- | --- | --- |
| руководитель МО | Заместитель директора по учебной работе | Директор |
| ________________________ | ________________________ | __________________ |
| Сайфутдинова Л.Н.<br>Протокол заседания МО №1<br>от «28» 08 2025 г. | Мифтахова К.С.<br>Пр №1 от «28» 08 2025 г. | Булатова Н.С.<br>Приказ № 410<br>от «29» 08 2025 г. |

# РАБОЧАЯ ПРОГРАММА

(ID 5353403)

**учебного предмета «Государственный (татарский) язык Республики Татарстан»**

для обучающихся 10-11 классов

**с.Усады Лаишевского муниципального района РТ 2025г.**

## ПОЯСНИТЕЛЬНАЯ ЗАПИСКА

Рабочая программа учебного предмета «Государственный (татарский) язык Республики Татарстан» для общеобразовательных организаций с обучением на русском языке (10-11 классы) основывается на Федеральный государственный образовательный стандарт Российской Федерации, конкретизирует и раскрывает его содержание, а также определяет общие направления обучения, воспитания и развития учащихся с учетом его целей. Она является примерной для дальнейшей реализации авторских программ и составления учебников.

Среднее (полное) общее образование учащихся старших классов по родному языку ставит перед собой цель: дальнейшее развитие коммуникативной, лингвистической и культуроведческой компетенций.

Изучение татарского языка в старших классах направлено на решение следующих задач:

- воспитание гражданственности и патриотизма;
- продолжение обучения в русле духовной, нравственной и культурной ценностей татарского народа;
- обучение специфическим особенностям татарского языка;
- совершенствование знаний, умений и навыков коммуникации на родном языке;
- воспритяие родного языка как общественного явления, соблюдая его нормы, развитие умений использования в связи с различными жизненными ситуациями;
- выделение языковых единиц, анализируя и сопоставляя их, развитие умения учащихся правильного употребления в повседневном общении между собой: в учебном процессе и во внеклассной работе;
- работа с текстом с целью извлечения необходимой информации и ее трансформации;
- умение использовать знания по родному языку в связной речи учащихся;
- умение использовать знания по родному языку в различных условиях коммуникации;
- развитие орфографической и пунктуационной грамотности учащихся;
- развитие умения учащихся общественной адаптации и положительного эмоционального воздействия своему собеседнику;

- сопоставление (при необходимости) языковых и речевых единиц татарского и русского языков.

Вышеперечисленные задачи реализуются в процессе развития различных компетенций.

В старших классах совершенствуются полученные знания, умения и навыки, возрастает степень самостоятельности учащихся в использовании языковых средств в повседневной жизни. Большое значение имеет освоение современных инновационных технологий обучения татарскому языку.

Особенности учебного предмета «Родной (татарский) язык» в 10-11 классах в образовательных организациях с обучением на русском языке обусловлены сформулированными выше целями и задачами изучения родного языка в старших классах.

По структуре в программе имеются три содержательные линии, обеспечивающие формирование и развитие вышеуказанных компетенций. Они взаимосвязаны между собой и обусловлены коммуникативной, лингвистической и культуроведческой компетенциями, получаемые дальнейшее совершенствование и развитие на уроках татарского языка.

## 1. ПЛАНИРУЕМЫЕ ПРЕДМЕТНЫЕ РЕЗУЛЬТАТЫ ОСВОЕНИЯ УЧЕБНОГО ПРЕДМЕТА «Государственный (татарский) язык Республики Татарстан»

Планируемые предметные результаты освоения с учетом общих требований Стандарта и специфики учебного предмета «Родной (татарский) язык»:

- формирование представлений о роли языка в жизни человека, общества и государства; через изучение русского, родного и иностранного языков и литератур к ценностям национальной и мировой культуры;
- возможность свободно общаться в различных формах и на разные темы в учебном процессе и во внеклассных мероприятиях;
- формирование позитивного эмоционально-оценочного отношения к татарскому языку, понимание значимости хорошего владения родным языком, стремления к его грамотному использованию;
- осознание значимости татарского языка как государственного языка Республики Татарстан;
- представление о языке как об основном средстве человеческого общения и явлении национальной культуры, о роли родного языка в жизни человека и общества;

- овладение изучаемыми нормами татарского языка (орфоэпические, лексические, грамматические, орфографические, пунктуационные), правилами культуры речевого поведения; использование этих норм для успешного решения коммуникативных задач в ситуациях учебной языковой деятельности и бытового общения; формирование сознательного отношения к качеству своей речи, контроля за ней;
- овладение основами грамотного письма, основными орфографическими и пунктуационными умениями; применение правил орфографии и пунктуации в процессе письма;
- овладение основными понятиями и правилами из области фонетики, графики, лексики, морфемики, грамматики, орфографии, а также умениями находить, опознавать, характеризовать, сравнивать, классифицировать основные единицы языка (звуки, буквы, слова, предложения, тексты); использовать эти знания и умения для решения познавательных, практических и коммуникативных задач;
- понимание значимости правильной устной и письменной речи как показателя уровня общей культуры человека.

**Ожидаемые результаты реализации программы**

Уровень владения родным языком учащихся старших классов должен соответствовать следующим требованиям:

- знают основные функции языка;
- осознают и понимают такие понятия, как «речевая ситуация», «литературный язык», «нормы языка» и др.;
- усвоили основные признаки и взаимосвязь языковых единиц и уровней языка;
- знают орфоэпические, лексические, грамматические, орфографические и пунктуационные нормы татарского литературного языка;
- умеют пользоваться нормами речевого этикета, относящиеся к общественно-культурной, научной, официально-деловой и бытовой жизни;
- умеют давать оценку устному и письменному высказываниям с точки зрения их формы и содержания;
- проводят лингвистический анализ текста;
- осознают тесную взаимосвязь языка, истории народа и культуры.

Умение пользоваться знаниями, полученными на уроках родного языка, отражается в следующем:

- чтение текста с учетом его жанрового своеобразия (ознакомительное, изучающее, реферативное и т.д.);
- умение извлечь необходимой информации с различных источников (научных, справочных, электронных (Интернет) ресурсов);
- использование различных приемов информативной трансформации устных и письменных текстов;
- написание текстов, отражающих деловую, научную и бытовую жизнь, в различном жанре и стилях, в монологической и диалогической формах;
- соблюдение в устной и письменной речи орфоэпических, лексических и грамматических норм татарского литературного языка;
- усвоение норм речевого этикета в различных сферах общения;
- соблюдение в письме орфографических и пунктуационных норм современного татарского литературного языка;
- соблюдение в речи и письме порядок слов, характерный для татарского литературного языка;
- умение в различных ситуациях общаться в устной и письменной формах на татарском литературном языке: в учебном процессе и во внеклассных мероприятиях;
- умение переводить с татарского на русский язык и с русского на татарский язык тексты (устные и письменные), разные по своему жанру и стилю.

## 2. СОДЕРЖАНИЕ УЧЕБНОГО ПРЕДМЕТА «Государственный (татарский) язык Республики Татарстан»

### 1. Содержание, обеспечивающее формирование и развитие коммуникативной компетенции

Речь. Речевая ситуация. Устная и письменная речь. Диалогическая и монологическая речь.

Выделение особенностей устной и письменной речи. Анализ отдельных примеров, относящихся к различным видам речи. Умение выделить цели коммуникации с учетом различных речевых ситуаций.

Язык и речь. Использование языковых единиц в речи. Виды речи: устная и письменная речь, диалогическая и монологическая речь. Основные единицы речи: слово, предложение, текст.

Речевая деятельность. Различные виды и культура речевой деятельности: чтение, аудирование, говорение и письмо.

Усвоение различных видов речевой деятельности. Умение определить основную и дополнительную информацию, содержащуюся в тексте.

Использование полученных из разных источников знаний на практике. Письменное общее (выборочное или краткое) изложение содержания прослушанного или прочитанного текста.

Составление монологических и диалогических текстов, систематизация выбранного материала в соответствии с обозначенной темой.

**1. Содержание, обеспечивающее формирование и развитие лингвистической компетенции**

Язык – средство общения, общественное и политическое явление. Основные функции языка. Роль родного языка в формировании личности человека.

Классификация языков. Тюркские языки. Татарский язык среди тюркских языков. Общие сведения о татарском языке.

Формы употребления татарского языка: литературный язык, диалекты, просторечие, профессиональная речь, жаргоны и др.

Татарский язык – язык татарской художественной литературы, средства его описания.

Осознание роли и места татарского языка в общественной и личной жизни человека; формы употребления татарского языка: литературного языка, диалектов, просторечия, профессиональной речи, жаргона и др.

Татарское языкознание и его разделы. Ведущие ученые татарского языка и методики преподавания.

Основные разделы татарского языка: фонетика, лексикология, словообразование, грамматика (морфология и синтаксис), орфография и пунктуация.

Фонетика. Орфоэпия. Графика. Звук. Фонема. Изменения гласных и согласных. Транскибирование слов. Ударение. Интонация. Орфоэпия. Орфография и его принципы.

Лексикология. Лексическое значение слова. Многозначность слова. Прямое и переносное значение слов. Понятие об этимологии. Фразеологизмы. Лексикография.

Морфемика и словообразование. Особенности морфемного строя татарского языка. Способы словообразования.

Грамматика. Понятие о грамматике. Разделы грамматики.

Морфология. Части речи в татарском языке. Морфологический разбор различных частей речи.

Синтаксис. Основные синтаксические единицы: слово, словосочетание и предложение. Синтаксис простого и сложного предложения.

Текст. Понятие о тексте, его основные признаки (деление на значимые взаимосвязанные части). Тема, идея и микротема текста.

Средства связи отдельных предложений и частей текста. Абзац как средство достижения композиционно-стилистической целостности текста.

Функционально-семантические типы речи: описание, суждение, осмысление. Структура текста. Составление плана и тезиса как средства обработки текста.

Анализ текста с учетом его тематики, основной идеи и структуры. Деление текста на семантические части и составление его плана. Создание текстов, различных по жанру и стилям с соблюдением соответствующих норм (последовательность, взаимосвязь частей, соответствие выбранной теме). Оценка, исправление устной и письменной речи, составление ее плана и тезиса.

Прямая и косвенная речь.

Пунктуация.

Стилистика  и культура речи. Функциональные стили татарского литературного языка.

**2. Содержание, обеспечивающее формирование и развитие этнокультурологической компетенции**

Расширение и углубление знаний о культуре своего народа и культуре народов Российской Федерации (известные достопримечательности, образцы литературы, выдающиеся люди и др.). Осознание старшеклассниками языка как формы выражения национально-культурной специфики татарского языка; расширение знаний о взаимосвязи развития языка и истории народа; совершенствование умений и навыков употребления этикетных норм общения со старшими и сверстниками в устной и письменной речи; соблюдение норм культуры межнационального общения в повседневной жизни.

В 10-11 классах актуализируются, обобщаются и углубляются знания и умения, полученные в предыдущих классах.

В процессе освоения раздела *“Фонетика. Орфоэпия. Графика”* **учащиеся научатся:**

- сделать фонетический анализ более сложных словоформ;
- соблюдать орфоэпические нормы татарского языка;
- извлекать необходимую информацию из орфоэпического словаря татарского языка и  справочной литературы и использовать ее в различных ситуациях общения.

**Учащиеся получат возможность:**

- различать средства выразительного чтения;
- выразительно читать различные по жанру текстов;

- извлекать необходимую информацию из орфоэпического словаря татарского языка и справочной литературы в мультимедийной форме и использовать ее в различных ситуациях общения.

В процессе освоения раздела *“Лексикология и фразеология”* **учащиеся научатся:**

- сделать лексический анализ слова с точки зрения его значения, происхождения, сферы и активности употребления;
- обобщать слова в тематические группы;
- определить лексические нормы в устной и письменной речи;
- установить лексическую синонимию во избежание тавтологических повторов, с целью достижения связной речи;
- выделить метафору, эпитет, олицетворение;
- использовать различные – толковые и фразеологические словари, а также словари синонимов и антонимов.

**Учащиеся получат возможность:**

- классифицировать лексический состав татарского языка;
- установить различие между лексическим и грамматическим значениями слов;
- оценить свою и чужую речь с точки зрения уместного, выразительного и точного использования лексических единиц;
- пользоваться лексико-фразеологическими средствами в текстах различных (публицистических и литературных, научных и официально деловых) жанров;
- извлекать необходимую информацию из различных словарей (толковых, синонимов, антонимов, иностранных слов, фразеологических) и мультимедийных средств.

В процессе освоения раздела *“Морфемика и словообразование”* **учащиеся научатся:**

- сделать морфемный анализ слов с нечеткими морфемными швами;
- определить способы образования слов и привести свои примеры;
- образовать от предложенного учителем слова однокоренные слова;
- распознать части речи и члены предложения исходя из морфемного строения слова.

**Учащиеся получат возможность:**

- установить семантическую связь между однокоренными словами;
- определить значение словообразовательных элементов в литературно-художественных текстах как описательного элемента;

- извлекать необходимую информацию из словообразовательного словаря татарского языка и справочной литературы в мультимедийной форме и использовать ее в различных ситуациях общения;
- выяснить этимологию слова с целью усвоения его орфографии и лексического значения.

В процессе освоения раздела *“Морфология”* **учащиеся научатся:**

- анализировать различные части речи;
- использовать различные формы частей речи в рамках норм современного татарского литературного языка;
- употреблять знания и навыки по морфологии для выполнения орфографических норм и проведения различных типов анализов.

**Учащиеся получат возможность:**

- выделять грамматические омонимы;
- использовать различные формы частей речи в публицистических и литературных, научных и официально деловых стилях;
- извлекать необходимую информацию по морфологии из различных словарей и мультимедийных средств.

В процессе освоения раздела *“Синтаксис”* **учащиеся научатся:**

- анализировать словосочетания и предложения с точки зрения структуры, значения и особенностей употребления при коммуникации;
- различать синтаксические формы частей речи в рамках норм современного татарского литературного языка;
- использовать знания и умения по синтаксису в процессе проведения различных анализов.

**Учащиеся получат возможность:**

- использовать синтаксические средства в текстах различных (публицистического и литературного, научного и официально делового) жанров;
- провести синтаксический анализ предложений с учетом их функционально-стилистических особенностей, использовать их в речи как выразительное средство.

В процессе освоения раздела *“Орфография и пунктуация”* **учащиеся научатся:**

- использовать орфографические и пунктуационные нормы в пределах программы;
- сформулировать устные или письменные комментарии орфографии отдельных слов;

- выделять и исправлять орфографические и пунктуационные недочеты.

**Учащиеся получат возможность:**

- понимать роль и значение соблюдения орфографических и пунктуационных норм в устной и письменной речи;
- извлекать необходимую информацию из различных словарей (толковых, синонимов, антонимов, иностранных слов, фразеологических) и мультимедийных средств и их правильное употреблять в речи.

В процессе освоения раздела *“Стилистика”* **учащиеся научатся:**

- определить научный, официально-деловой и публицистические стили и их жанровые особенности;
- установить специфику подготовки выступлений перед аудиторией (товарищами): обозначить его тематики, определить цели и задачи;
- учитывать возрастные и психологические особенности вовлечения лингвистического материала в свое выступление, его соответствие уровню знаний, умений и навыков учащихся.

**Учащиеся получат возможность:**

- отличать специфику устной и письменной речи;
- работать с текстами различных жанров и стилей (чтение готового текста или его трансформации в соответствии с обозначенными целью и задачами);
- переводить с татарского на русский язык и с русского на татарский язык различные по жанру и стилям тексты с соблюдением норм устной и письменной речи.

В процессе освоения раздела *“Язык и культура”* **учащиеся научатся:**

- выделить лингвистические единицы с этнокультурным компонентом в произведениях устного народного творчества, а также произведениях, созданных в жанре исторических романов и др.;
- находить яркие примеры произведений, утверждающие мнение о том, что изучение языка способствует лучшему усвоению истории свой страны и культуры;
- изучать правила татарского речевого этикета с целью уместного их употребления в повседневной жизни: в учебном процессе и во внеклассной работе.

**Учащиеся получат возможность:**

- описать на примере изучаемых произведений тесную связь языка с историей культуры народа и его истории;
- охарактеризовать татарский речевой этикет в сравнении с этикетом других народов Российской Федерации.

## 3. ТЕМАТИЧЕСКОЕ ПЛАНИРОВАНИЕ

**10 класс- 102 часов**

**Блок 1. - 20часа**

Язык – средство общения, общественное и политическое явление.
Основные функции языка. Роль родного языка в формировании личности человека.

Классификация языков. Тюркские языки. Татарский язык среди тюркских языков. Общие сведения о татарском языке.

**Блок 2.-37 часов**

Основные разделы татарского языка: фонетика, лексикология, //словообразование, грамматика (морфология и синтаксис), орфография и пунктуация.

Фонетика. Орфоэпия.
Графика. Звук. Фонема.
Изменения гласных и согласных. Транскрибирование слов.
Ударение. Интонация.
Орфоэпия. Орфография и его принципы.

Лексикология.Лексическое значение слова. Многозначность слова. Прямое и переносное значение слов. Понятие обтэтимологии. Фразеологизмы. Лексикография.

**Блок 3. -18 часов**

Морфемика и словообразование.

Особенности морфемного строя татарского языка. Способы словообразования.

**Развитие речи- 27 часов**

**11 класс- 102 часов**

**Грамматика. -10час**

Понятие о грамматике. Разделы грамматики.

**Морфология. -20ч**

Части речи в татарском языке. Морфологический разбор различных частей речи.

**Синтаксис. -20ч**

Основные синтаксические единицы: слово, словосочетание и предложение. Синтаксис простого и сложного предложения.

**Текст. -18часов**

Понятие о тексте, его основные признаки (деление на значимые взаимосвязанные части). Тема, идея и микротема текста.

Средства связи отдельных предложений и частей текста. Абзац как средство достижения композиционно-стилистической целостности текста.

Функционально-семантические типы речи: описание, суждение, осмысление. Структура текста. Составление плана и тезиса как средства обработки текста.
Анализ текста с учетом его тематики, основной идеи и структуры. Деление текста на семантические части и составление его плана. Создание текстов, различных по жанру и стилям с соблюдением соответствующих норм (последовательность, взаимосвязь частей, соответствие выбранной теме). Оценка, исправление устной и письменной речи, составление ее плана и тезиса.

**Прямая и косвенная речь.-12часа**

**Пунктуация.-10часа**

**Стилистика  и культура речи. -6ч**

Функциональные стили татарского литературного языка.

**Развитие речи-6часов**

Приложение 1

**Контрольно-измерительные материалы.**

**10класс**

**1.Диктант**

**Рәхмәт, Тормыш!**

Рәхмәт сиңа, кояш! Түп-түгәрәк булып тау артыннан көлә-көлә килеп чыкканың өчен. Көлүен бар дөньяга нур булып бөркелә. Сиңа үрелеп, гөлләр булып үсәбез, синдә наз, синдә яшәү, синдә шатлык.

Рәхмәт сиңа, җил! Ачык тәрәзәмнең челтәр пәрдәләрен җилфердәтеп, чәчләремә йомшак кагылып, күңелемне җилләндергәнең өчен. Рәхмәт, җилкәй, бакчамдагы шомырт, сирень чәчәкләренең хуш исләрен миңа бүләк иткәнең өчен.

Рәхмәт сезгә, Туган җирем, болыннарым, тугайларым, кырларым! Рәхмәт сезгә, тәмле сулы чишмәләрем! Бер йотым суыгызда — мең дәва.

Рәхмәт, Тормыш! Сынауларыңа сынмаслык рухи көч биргәнең өчен. Матурлыкны күреп, яхшылыкны тоеп яшәү сәләтемнән аермавың очен. Кыенлыклар килгәндә, дулкын булып ярларга кагам, кош булып кыяга бәреләм, давыл булып шашам. Ә шулай да Кеше булып калу матуррак.

Рәхмәт, Тормыш! Кеше булып яшәвемне таләп иткәнең өчен. *(115 сүз.) (К. Шәфыйковадан)*

**Биремнәр.**

1.Тексттан ясалма сүзләрне табып, асларына сызарга.

2.*Болыннарым* сүзендәге сузык авазларга характеристика бирергә.

**Дуслык ничек туа?**

Зур панельле йортлар сала башлагач, ай-һай кызуга китте төзүчеләрнең эшләре. Печән кибәне хәтле экскаваторларның, яман уылдап, әреме-куагы, ташы-ние белән җирне умыртырга тотынуы була, машина-машина стена, йөге-йөге белән ишек-тәрәзәләр, идән-түшәмнәр китереп аударалар да, әкияттәге батыр шикелле, күз ачып йомганчы, биш-алты катлы йортларны утырталар да куялар, утырталар да куялар. Бер-бер аралы тезелеп кенә тора яңа урамнар. Көзен Камилләр Беренче Аркылы урамга күчеп килгәннәр иде. Хәзер

андый урамнар җидәү. Тиз генә исем табып бетерүе дә читендер шул, барысына да Аркылы дип кушканнар.

Беренче Аркылы урамнан җиденче сыйныфта ике генә малай укый. Аларның берсе — Камил, түп-түгәрәк битле, кьсынкырак кара күзле, таза гәүдәле, авыр хәрәкәтле укучы, икенчесе — аның партадаш дусты Алик. Ул да гәүдәгә артык зур түгел, тик бөтерчек шикелле җитез, һәрвакыт каядыр ашыга, нәрсәгәдер омтыла, кызу-кызу сөйләшә, иптәше бер сүз әйткәнче, ул унны ычкындырып өлгерә. Озын керфекләр астына яшеренгән зур сөрмәле күзләре генә сабыр, уйчан һәм малайның хәрәкәтчән, җыйнак гәүдәсенә ничектер ят булып тоела. Камилләр дә, Аликлар да бу урамга бер үк көнне күчеп килделәр. Бер үк йортның бер катына да туры килделәр әле, җитмәсә. Ишекләре кара-каршы гына тора. Беренче көнне үк дуслаштылар алар.

Бишенче урам малайлары Камалләрнең авызына гына карап тора: соңрак килгәнгәдер инде, алар кыюсызрак әле, кунак шикелле, әдәпле тоталар үзләрен.

Шулай да озак бармады бу хәл. Кышкы каникулдан соң аларның сыйныфына тагын бер малай килде. Озын буйлы, киң җилкәле. Беләк һәм күкрәп мускуллары, гимнастеркасын тартып, тыгызланып тора. Килгән көнендә үк белделәр Камилләр: Фоат атлы бу малай җәен-кышын йөзү бассейнына йөри икән. Укучылар арасында йөзү буенча республика чемпионы да үзе.

Тышкы кыяфәте белән үк башкалардан аерылып торган Фоат, атна-ун көн дә үтмәде, сыйныфны үз кулына алды да бетерде. Хәер, Камил белән-Алик беренчелек өчен бәхәсләшергә уйлап та карамадылар. Чемпион хәтле чемпион белән дуслашу аларның үзләре өчен дә кызык иде.

Ә Фоат чыннан да шәп малай булып чыкты ул. Иң элек, Камил белән Алик шикелле тererәк малайларны җыеп, йөзүчеләр түгәрәге оештырды. Йөзүчеләр дип аны Фоат белән шул түгәрәккә йөргән малайлар гына чын күңелдән әйтә инде. Ә калганнары ачулары килгәндә, *я* үртәргә кирәк булганда шулай диләр. Чөнки Аликларның түгәрәккә йөри башлаганнан бирле бер тамчы да су күргәннәре юк әле. Физкультура залына алып керә дә Фоат аларны, идәнгә яткырып, йөзү хәрәкәтләре ясарга өйрәтә, я җыелган саен гимнастика эшләтеп йөдәтә. Дөрес инде анысы, түгәрәк утырышлары шәһәрнең йөзү бассейнында үтсә, мең кат әйбәт булыр иде дә бит. Фоат әйтә: «Анда йөрүчеләр болай да бик күп, алдан өйрәнеп барсак, үзебез өчен яхшырак булыр»,— ди. Түзәләр инде Камилләр. Сыйныфташларының үртәүләренә дә, бертөрлелеге белән туйдырып бетергән гимнастика алымнарына да түзәләр. Аның каравы, язга чыккач, йөзү ярышлары башланып китсә, үртәп теңкәгә тиючеләр үзләре йөрерләр әле йөзүчеләр артыннан.

Тик бер ягы җитми Фоатның, грамматика белән дус түгел. Шулай да бирешергә

чамасы юк малайның. Теше-тырнагы белән чытырдатып ябышкан ул дөрес язу кагыйдәләренә, тартышыпмы-тартыша. Үзенең генә көче җитмәгәч, иптәшләренең ярдәменә таянырга булды ул. (415 сүз)

*Л. Ихсановад.*

**3.Диктант**

**Колын**

Җәй башында безнең җирән кашка колын алып кайтты.

Хәзер мин, бүтән уеннарымны онытып, көнозын колын тирәсендә бөтерелә башладым. Иртән торуга иң беренче куанычым шул: ипи йомшагы эләктерәм дә колын янына чыгам. Баштарак ул, мин янына керүгә, тизрәк анасына барып сыена торган иде. Тора-бара иялэнде. Мин дәшкәч, колакларын торгызып, борылып карый торган булды, Бераздан, матур борын тишекләрен селкеткәләп, ипи исни башлады. Аннары көл төсле зәңгәрсу-соры, хәтфә кисәге шикелле йомшак иреннәре белән уч төбеннән ипи сыныклары эләктереп алырга өйрәнде.

Өммикамал апа зәңгәр сатиннан муенса тегеп биргәч, колынның муенына кечкенә генә шөлдер тагып җибәрдек. Колын башын селкеткән саен, ул гаҗәп сөйкемле тавышлар чыгара, әйтерсең, чың-чың итеп, берьюлы әллә ни тикле көмеш тәңкә коела. (110 сүз)

*Г. Бэширов*

**Бирем**

Күп иярченле кушма җөмләне аерып язарга, схемасын төзергә, төрен күрсәтергә.

**Кызару**

Җәйге каникулны да бергә үткәрергә уйлап, мин Ногманны үзебезнең авылга алып китәргә булдым. Башта ул бераз уңайсызланып торса да, соңыннан риза булды. Зачетларны да уңышлы биреп тынычланып калгач, бик күтәренке күңел белән юлга чыктык. Без төшәсе станциягә килеп җиткәнче, андый-мондый нәрсә булмады. Вагоннан төшкәч тә, Ногманны багажлар янына утырттым да ат эзләргә киттем, чөнки безнең авылга барып җитәргә егерме чакрымлап бар иде әле. Станциянең аргы ягына чыксам, бер ат әкрен генә юыртып китеп бара. Аны кычкырып туктаттым, янына бардым. Арбада ак яулыгын артка чөеп бәйләгән, кара күлмәк өстенә күк төстәге атланмалы алъяпкыч кигән бер хатын утыра. Карыйм — моның тут баскан битләрен, кап-кара күзләрен кайдадыр күреп калган кебек тоям. Кинәт исемә Ногманның акчасы югалган көнне безнең уртадан капчык күтәреп үтеп киткән хатын килеп төште. Нинди кызыклы очрашу. Аңа карап

тукталып тормадым, аның кайсы авылга кайтуын сорадым. Аның юлы нәкъ безнең авыл аркылы үтәргә тиеш икән, ул безнең күрше авыл хатыны булып чыкты. Хатын безне утыртып алып кайтырга башта риза булмады. Атка правление рөхсәтеннән башка беркемне дә утыртып йөрергә хакы юклыгын әйтте. Ләкин, үтенеп сорагач, правлениегә барып, километр исәбеннән куелган бәядән хак түләү шарты белән генә утыртырга мөмкинлекне әйтте. Мин, акча түләү өчен күрше авылга барып йөрү кыенлыгын күз алдында тотып, акчаны аның үзенә генә тәкъдим итеп карадым. Ләкин ул бик кырку гына тавыш белән:

— Ничек инде ул, куелган тәртипне бозарга кушасызмыни, акча минем кесәдә калсын дисезмени? Мондый «яхшылык» өчен сезгә бик рәхмәт инде,— дип, мине нык кына кызартты.

Мин чемоданнарны арбаның бер як үрәчәсенә сөябрәк салдым да алар белән янәшәләп үзем дә утырдым.

Юл буенча Ногман бернәрсә дә сөйләшмәде. Мин генә, хатынның тормышына кагылырдай сораулар биргәләп, аның яшь кенә көе тол яшәвен, исеменең Фәрихә икәнлеген белеп алдым.

Бер урында тау менәсе булгач, без төшеп җәяүләдек, Фәрихә, ат тотучы булганлыктан, арбадан төшмәде. Көн бик эссе иде, Ногман кесәләрендәге барлык әйберләрен бушатып чалбар кесәсенә тутырды да өстен салып арбага илтеп куйды.

Тауны менеп җиткәч тә, икебез дә арбага менеп утырдык. Ат юырта башлагач, Ногман аякларын күтәреп арба читенә елышты. Фәрихә дилбегәне тарткан саен, ат, соры тузаннар туздырып, чапты да чапты.

Бераздан безнең авыл күренде.

Без авылга килеп җиттек.

Фәрихә, мин бик кыстасам да, чәй эчәргә дә кермәде, гадәттәгедән дә ныграк куа-куа, бик кызу китеп барды. Без өйгә кердек. Күрешү, ыгы-зыгы китте. Шул вакытта ике кулын да чалбар кесәләренә батырган Ногман кычкырып җибәрде:

- Слуши, Сәлим! Минем акча да, документлар да юк бит!

Өй эчендәгеләр дә, мин дә аптырап калдык. Бу ни хәл бу?

Чынлап та Ногман хаклы булды микәнни? Төрлечә уй йөртү, кычкырып сөйләшү китте. Мин: «Бәлки, чалбар кесәңнән арбага шуып төшеп калгандыр, табылмасмы әле»,— дип, Ногманны өметләндерергә тырышып карадым. Ногман миңа каты итеп җавап бирде:

- Бар, эт авызына кергән сөякне алып кара хәзер. Алыр сың, табарсың!

Нәкъ шул вакытта ишек төбендә Фәрихә күренде. Кап-кара күзләрендә шелтә

чагылдырып, Ногманга текәлде:

- Мәгез әйберләрегезне. Бигрәк каты әйтәсез икән. Алай таралып йөрергә ярамый. Әле яхшы, арба төбе тишек булмаган. Хушыгыз.

Ногман гүя телен йотты, хәтта «рәхмәт» дип тә әйтә алмады, аның битенә куе кызыллык йөгергән иде. (489 сүз)

**6. Контролный диктант**

**Беренче яңгыр**

Язның беренче яңгыры кинәт килде. Таң беленер-беленмәстә, көньяк-көнбатыштан кабарып чыккан болыт ерактан торып бер-ике тапкыр гөлдерәп тавыш бирде дә, әкияттәге Каф тавыдай калкып, ярты күк йөзен томалады. Тау артыннан кояш күтәрелә башлауга, ул, киң кара-кучкыл канаты белән көнне тагын да караңгылатып, бөтен күк йөзен каплады.

Күп тә үтмәде, салкынча яңгыр җиле Карамалы урамнарында өермә кузгатты. Кар сулары киткәннән бирле битен-күзен бер тапкыр да юмаган агачлар яңгыр килгәнне сизеп шаулашып куйдылар.

Бераздан, урам-тыкрыклардагы чүп-чарны бөтереп, өермә җиле узды. Нава, афәт көткәндәй, берара тынып торды. Менә шунда, һәммә нәрсә, барча тереклек инде тагын ни булыр дип көткәндә, күк йөзен икегә ярып, яшен яшьнәде, һәммә җан иясе сискәнеп куйды, чөнки яшен артыннан чытырдап күк күкрәде. Беренче курку үтеп, күк йөзе тагын дөбердәгәч, эре-эре яңгыр тамгалый башлады, ә берничә минуттан чиләкләп коярга тотынды.

Яңгыр әллә ни озак яумады сыман, әмма юл-сукмакларга су җыелды; шаулап, гөрләвекләр агып китте. (143 сүз)

*М. Хэбибуллин*

**Бирем**

Соңгы җөмләнең төрен билгеләргә һәм тыныш билгеләрен аңлатырга.

**11 класс**

**1.Диктант**

**Халкыбызның моң иясе**

Бөтен татар дөньясының горурлыгына әверелгән бу исемне һәр тарафта яратып телгә

алалар. Жырчы Илһам Шакиров турында күп язылган, кинолар төшерелгән, шигырьләр иҗат ителгән, җырлар чыгарылган... Халкыбызның моң иясе булып танылган Илһам Шакиров үзе исән чакта ук рухи асылыбызны чагылдыручы зат булды, җыр дөньясының олпат улы була белде.

Бүген дә аңа булган илаһи мәхәббәт һәр татар күңелендә үсә бара. Халкыбыз үзенең Илһамыннан илһамланып яши, тулы мөстәкыйльлеккә юл яра.

Ходай биргән сәләте янында тагын 99 процентка торышлы тырышлыгы булганга, без хәзерге Илһамны беләбез. Аның тору урыны да, яшәү урыны да татар тамашачысы белән тулы залларның сәхнәсе булды.

Халык аны зурлады, әмма ул эреләнмәде, тәкәбберләнмәде, масаймады, байлык артыннан кумады, сарайлар салмады. Аның алтын сарайлары — халык күңелендә.

Илһам Шакиров татар җырындагы илһамлык серенә теләсә кемгә караганда да тирәнрәк төшенде. Шуңа да бит аңа бөтен татар дөньясы табынды һәм хәзер дә табына.

Сер түгел: Илһам Шакиров исемен ишетүгә, күңелләр канат кагына, тормышлар акланып, пакьләнеп, сафланып киткәндәй була.

Әйе, саекмас моңы белән барыбызны да әсир итә, аның җырлавын халык бөтен җаны, бөтен йөрәге белән көтә. Ә ул, бәгырьләрне теләтелә, халкы өчен җырлый да җырлый.
(190 сүз) *«Казан утлары» журналыннан*

**Акъәби**

Акъәбинең соңгы еллардагы гомере балаларының кайтып китүләрен көтеп яшәү белән генә уза башлады. Дөрес, моннан ун ел элек, карты үлгәннән соң, балалары карчыкны калага тартып караганнар иде каравын, ләкин Акъәби гомер иткән нигезен ташлап китәргә теләмәде инде. Шушы Юлкотлыда туган ул, шушында гомер буе яшәгән, уллар-кызлар үстергән. Шушы Юлкотлы туфрагында аның атасы, анасы, күпме туганнары, яшьли үлгән сабыйлары, гомер иткән карты ята —я, ничек шуларның барысын да ташлап китәсең? Күп торасы да калмагандыр, ят җирнең туфрагына барып ятканчы, шушында үзенекеләр янында булыр дип уйлаган иде карчык ул чакта. Һәм, һичнигә карамастан, хәзергә чаклы ул шушы нигезендә нык торды. Бигрәк тә оныкларын бик сагына карчык. Шулар кайтса инде, куанычы эченә сыймый, бөтен дөньясын онытаТик бу бәләкәчләрнең әти-әниләре карчык янына гадәттә бик кыска вакытка гына кайталар.

Нишлисең, заманасы шулай туры килде инде. Акъәбинең сабый чактан исән

калган балалары үсә тордылар, күрше авылның урта мәктәбен бетерә тордылар, һәркайсы, канат чыгарып, кош кебек, Юлкотлыдан еракка оча тордылар. Хәзерге вакытта бер улы белән бер кызы Өфедә яшиләр. Тагын бер кызы, врач булып чыкканы, Пермь өлкәсендә тора, ә иң кече малае, институтны бетергәч, Казакъстанга җибәрелгән иде, шунда — исеме дә билгесез бер шәһәрдә — кемдер булып эшли.

Өфедәге иң зур улы Суфиян, кызы Гөлбикә фәнни институтларның берсендә гыйльми эштә, кияве исә зур, җаваплы урында утыра. Кыскасы, барысы да зур кешеләр булып беттеләр. Кайсы галим, кайсы инженер, кайсы врач...

Тик менә бик бәхетле булып киткән балалары аңардан, ничектер, ераклаштылар шикелле... Менә зур улы Суфиян. Беркайда да эшләми, зур пенсия ала, машинасы бар, аңа бит Юлкотлыга ешрак кайтса да була хәзер... Ләкин, нишләтәсең аны, һаман вакытым юк дип зарлана, ниндидер комиссияләрдә эшләп йөри, кышын бер-ике айга курортка китә, я булмаса үзе кебек погоннарын салган полковниклар белән төннәр буе карта сугып утыра, ә җәйгә чыккач, машинасына хатынын, бала-чагаларын утырта да я Кырымга, я хатынының урыс туганнарына — Саратовка китеп бара. Ә каладан йөз егерме чакрымда гына торган Юлкотлы читтә кала, әнисе-карчыкның алар өчен генә дип саклаган казлары келәтендә шул килеш эленеп тора.

Шулай да былтыр җәй Суфиянның җиткән улы Геннадий үзләренең машинасында «бабушканы» күрергә дип кайткан. Өч көн торды, өч көн Акъәби бер кәлимә башкортча белмәгән оныгы алдына барлык сыйларын куйды, сүзсез генә аңа моңсу һәм назлы итеп карап утырды.

Менә шулай Акъәби, ялгыз башы улларын, кызларын көтеп, оныкларын сагынып, исән-имин генә яшәп килде. Әмма быел урынга ук ятарга мәҗбүр булды. (380 сүз)

Ә. Еникидән

**3.Диктант**

**Зәңгәр яулык.**

Каен ботагында зәңгәр **ефәк** яулык җилферди. Җилгә ияреп **очып** китмәкче дә була, үзе кебек зәп-зәңгәр күккә менеп очып йөрмәкче, ахры. Ычкына алмый шул— бәйләп куелган. Очып китә алса, болытлар өстенә кунып ял итәр иде. Берәрсе, урманга килгәч, югалмасын дип бәйләп куйгандыр да аны, онытып калдыргандыр, мөгаен. Бәлки кемнеңдер башыннан шуып төшкәндер дә, җил очыртып алып киткәндер?

Яулык җилферди дә җилферди. Ничек кенә булса да очып китәсе килә аның. Үзенә бер минут та **тынгылык** бирмәүче җилләрдән туйгандыр шул инде. Тын гына берәрсенең җилкәсенә кунасы киләдер. Я булмаса, кемнеңдер назлап кына **муеныннан** кочаклап алып,

чәчләрен ябарга телидер әле. Кем белә, бәлки менә-менә иясе килеп чыгар да, яулыкны, ниһаять, бу рәхимсез җилләр кочагыңнан коткарып, **кадерләп** муенына салыр...

Үземне әнә шул зәңгәр яулыкка охшатам. Еллар, айлар, көннәр җилендә, бөтереләбөтереләә, үз парымны эзлим. *(131 сүз.)*

*(М. Галимовадан)*

**Бирем.** 1. Билгеләнгән сүзләрне транскрипциядә бирергә.

2. Тексттан кереш сүзләрне табып, асларына сызарга, нинди мөнәсәбәт белдерүләрен җәя эчендә күрсәтергә.

3. Фигыльләрне кайтым юнәлешенә (-ын,-ен,-н) куеп язарга: *бизә-; макта-; сөрт-; сиз-; кара-; ки-; кап-.*

**Туган тел**

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!

Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.

Иң элек бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән,

Аннары төннәр буе әбкәм хикәят сөйләгән.

И туган тел! Һәрвакытта ярдәмең берлән синең,

Кечкенәдән аңлашылган шатлыгым, кайгым минем.

И туган тел! Синдә булган иң элек кыйлган догам:

Ярлыкагыл, дип, үзем һәм әткәм-әнкәмне, Ходам!

Үзенең туган телгә булган мәхәббәтен татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукай әнә шулай матур итеп әйтеп биргән. Чынлап та, туган телне чын мәгънәсендә ярату туган илне, әткәң-әнкәңне ярату белән бер ул. Туган телне юкка гына ана теле дип атамаган шул халык!

Бөек әдип Габдулла Тукай туган телне ярата белеп яраткан. Ул телне бары тышкы ямь бирү чарасы, матур аһәңнәр җыелмасы итеп кенә карамаган, аны иң элек аралашу, аңлашу, тәрбия һәм үсү коралы итеп таныган. Шуңа күрә дә Г. Тукай телне, халыкча итеп, туган тел, матур тел, әткәм-әнкәмнең теле дип атаган. Шагыйрьнең туган телне яратуы туган илгә булган мәхәббәте белән үрелеп килә, аның аерылгысыз өлешен тәшкил итә.

Туган тел төшенчәсенә зур мәгънә салынган. Ул- туган *җир, ата-ана* сүзләре белән бер үк дәрәҗәдә тора торган бөек, изге һәм кадерле сүз. Ул телне тугач та ишетә һәм өйрәнә башлыйсың, шуңа күрә аны туган тел дип атыйлар да. Ул телгә баланы башлап аның иң газиз кешесе — анасы өйрәтә, шул телдә аңа бишек җырлары җырлый, иркәли, юата. Шуңа күрә халык аны ана теле дип йөртә дә.

Телне кешелек җәмгыяте тудырган һәм кешелек җәмгыяте үстерә, ә тел, үз чиратында, хезмәт белән бергә, кешене кеше итә, үстерә. Шуңа күрә туган телне кеше үз баласын яраткан кебек яратырга, тәрбияләргә тиеш. Әмма баланы, чиктән тыш яратып тормышка яраксыз хәлгә китергән кебек, телне дә, фанатикларча «яратып», тормыштан аерырга һәм иҗатчысын — халыкны аннан биздерергә мөмкин. Ләкин шунысы яхшы: мондый күренешләр тарихта бик сирәк була, чөнки җәмгыять үсеше моңа ирек куймый, тел өлкәсендәге ялгышларны, кемнең кем булуына карамастан, төзәтеп бара.

Безнең туган телебез татар теле дип атала. Ул, аерым тел буларак, бер-берсенә якын булган болгар һәм кыпчак телләренең бергә аралашуы нәтиҗәсендә формалашкан. Хәзерге көндә татар телендә 6 миллион кеше сөйләшә.

Татар теле — зур тарихлы, бай телләрнең берсе. Хәзер телебезнең сүзлек составы бик нык баеды, грамматикасы камилләште. Татар теленнән файдалану мөмкинлекләре дә киңәйде. (308 сүз)

*М. Зәкиевтән*

**План**

*1. И туган тел, и матур тел...*

*2. Бөек шагыйрьнең туган телгә мәхәббәте.*

*3. Ана теленең бөеклеге.*

*4. Татар теле — бай тарихлы телләрнең берсе.*

**Сорау**

*Туган тел турында нинди китаплар укыганыгыз бар, аның турында тагын ниләр беләсез?*

**Бирем**

*Туган тел турында мәкальләр һәм әйтемнәр уйларга.*

**5.Контрольный диктант**

**Син сазыңны уйнадың**

Әдәбиятыбызның аксакалы...Нәкый Исәнбәт... Татар халкының җаны, намусы, йөзек кашы, талантлы драматург, шагыйрь, фольклорчы. Озын-озак, бәрәкәтле гомерен ул халыкка хезмәт итүгә багышлаган. Татар халкының тел, әдәбият хәзинәләрен җыю, барлау, гыйльми өйрәнү һәм аларны системага салып бастырып чыгару өлкәсендә армый-талмый эшләгән күренекле галим да Аның тарафыннан әзерләнгән һәм кырык меңгә якын берәмлекне эченә алган өч томлык «Татар халык мәкальләре», илле мең берәмлектән

торган фразеологик сүзлек, зур күләмле «Татар халык табышмаклары» һәм балалар фольклоры җыентыклары татар халык авыз иҗатын өйрәнү юлында фән ирешкән беренче фундаменталь хезмәтләр булып саналалар. «Татар халык мәкальләре» китабы өчен әдип-галимгә 1968 нче елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге бирелде.

Нәкый Исәнбәт 1899 нчы елның 29 нчы декабрендә элекке Уфа губернасының Златауст өязе Малаяз авылында мулла гаиләсендә туган. Уфадагы «Хәсәния», аннары Казанның «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый. Иҗат эшенә ул бик яшьли керешә. Ләкин гомер юлы сикәлтәле, сынауларга, кыенлыкларга бай була. Беренче шигырьләре «Сөембикә», «Аң» журналларында басыла. Ә «Уракчы кыз», «Син сазыңны уйнадың», «Бормалы су», «Илкәем» кебек җырлары, ничәмә-ничә дистә еллар буе халыкның үз җырлары булып, әллә ничә буынның мәхәббәтен казанып, телләрдән төшми, һаман җырлана. Шулай да аңа иң зур шөһрәт-танылуны драма әсәрләре китерә. Ул бер-бер артлы утыздан артык сәхнә әсәрләре — комедия, драма, трагедияләр иҗат итә.

Укымышлы галим, халкыбызның горурлыгы һәм мактанычы, күренекле әдип-драматургның исеме дә, иҗаты да онытылмый. Халкыбыз бу олпат ирне хөрмәт, ихтирам ярату белән күңелендә саклый. (211 сүз)

*Г. Исәнбәттән*